ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 59-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары О.М. Воронова, А.Р. Зарипов, Д.З. Зарипов, С.М. Захарова, Л.Н. Маврина, А.Р. Нәбиева, Р.Р. Нигъмәтуллин, И.Г. Хәнипов, В.Г. Чагин, Т.Н. Шаһивәлиев, Р.А. Шиһабетдинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 59-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 28 марты
№ 243-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары
О.М. Воронова, А.Р. Зарипов, Д.З. Зарипов,
С.М. Захарова, Л.Н. Маврина, А.Р. Нәбиева,
Р.Р. Нигъмәтуллин, И.Г. Хәнипов,
Т.Н. Шаһивәлиев, Р.А. Шиһабетдинов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) экстремизм, агрессив милләтчелек идеологиясенә, ксенофобия, коррупция чагылышларына, социаль, дини, раса, милли билгеләр буенча дискриминациягә һәм башка тискәре социаль күренешләргә һәм деструктив идеологиягә каршы торырга мөмкинлек бирә торган әхлакый һәм мәгънәви ориентирлар системасын булдыру;»;

2) 4 статьяның 2 пунктында «Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарының» сүзләреннән соң «, «Сириус» федераль территориясе гавами хакимият органнарының» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. Яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре

Яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, шул исәптән яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен тормышка ашыруга ярдәм итә торган гамәлләрне, чараларны эшләү һәм башкару;

2) Татарстан Республикасы яшьләренең социаль ихтыяҗларын, милли традицияләрне, региональ, җирле һәм этномәдәни үзенчәлекләрне исәпкә алып, яшьләр сәясәте өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу;

3) Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын билгеләү (алга таба – яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы);

4) Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, экологик, демографик, этномәдәни һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, яшьләр сәясәте өлкәсендә төп юнәлешләр буенча, шул исәптән яшьләрдә мораль-әхлакый кыйммәтләр тәрбияләүгә, татар халкының һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның традицияләренә, гореф-гадәтләренә һәм мәдәниятенә кызыксыну һәм ихтирам булдыруга юнәлдерелгән республика программаларын һәм муниципальара программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру;

5) яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка субъектлары дәүләт хакимияте органнарының ведомствоара үзара эшчәнлек тәртибен билгеләү;

6) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерүгә ярдәм итү, шул исәптән яшьләр сәясәте учреждениеләрен булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;

7) яшьләр белән эшләүче белгечләрнең эшчәнлеген оештыру;

8) Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны оештыру һәм башкару;

9) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләрне эш белән тәэмин итүгә, хезмәт кыйммәтләре формалаштыруга һәм гамәли күнекмәләр алуга, шул исәптән студентлар отрядлары оештырып, ярдәм итү;

10) Татарстан Республикасы яшьләре тарафыннан күрсәтелә торган тәкъдимнәрне, шул исәптән инициатив проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм итү;

11) яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләрендә, мәгариф эшчәнлеген башкара торган оешмаларда тәрбия эшенең төрле рәвешләренә ярдәм итү һәм аларны үстерү;

12) яшьләрне сәламәтләндерү һәм аларның ялы өчен шартлар тудыру;

13) яшьләрне экологик агарту һәм табигатьне яклау, әйләнә-тирә мохит торышын саклау һәм яхшырту чараларына җәлеп итү;

14) яшь гражданнарга психологик-педагогик ярдәм һәм социаль җайлашу өчен шартлар тудыру;

15) яшьләр сәясәте өлкәсендә Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән башка вәкаләтләр.»;

4) 6 статьяда:

а) беренче абзацта «Яшьләр сәясәте» сүзләрен «1. Яшьләр сәясәте» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$) муниципаль берәмлек территориясендә яшьләр сәясәте инфраструктурасын үстерүгә ярдәм итү, шул исәптән муниципаль яшьләр сәясәте учреждениеләрен булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү;»;

в) 4 пунктта «сәясәтен гамәлгә ашыруның» сүзләрен «сәясәтенең» сүзенә алмаштырырга;

г) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$) муниципаль берәмлек яшьләре тарафыннан күрсәтелә торган тәкъдимнәрне, шул исәптән инициатив проектларны гамәлгә ашыруда ярдәм итү;»;

д) 5 пунктта «мониторинглауны» сүзеннән соң «, шул исәптән яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглауны,» сүзләрен өстәргә;

е) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Муниципаль берәмлекләр башлыклары яшьләр сәясәте өлкәсендә координация органнары булдырырга хокуклы. Муниципаль берәмлек башлыгы каршындагы яшьләр сәясәте өлкәсендә координация органын булдыру тәртибе муниципаль берәмлек башлыгының хокукый акты белән билгеләнә.»;

5) 7 статьяда:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 статья. Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре»;

б) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) яшьләргә патриотик тәрбия бирү;

2) яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү;

3) яшьләр арасында милләтара (этникара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү, яшьләр иҗтимагый оешмалары эшчәнлегендә экстремизм чагылышларын профилактикалау һәм кисәтү, яшьләрдә Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә терроризмны, экстремизмны, башка деструктив идеологияне кабул итә алмау тәрбияләү, шулай ук аларны пропагандалауга каршы торучанлык булдыру;

4) яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итү;

5) авыр тормыш хәлендә калган яшь гражданнарга, яшь гражданнар арасыннан булган инвалидларга һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларга, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга ярдәм итү, шулай ук яшьләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтүдә ярдәм итү;

6) яшьләр инициативаларына, шул исәптән инициатив проектларына ярдәм итү;

7) яшьләргә ярдәм итүгә юнәлдерелгән иҗтимагый эшчәнлеккә булышлык күрсәтү;

8) яшьләрнең буш вакытын, ялын, аларны сәламәтләндерүне оештыру, яшь гражданнарны социаль һәм ил эчендәге туризмга җәлеп итү, шул исәптән табигый мохит шартларында уздырыла торган походлар, экспедицияләр, слетлар, фестивальләр һәм башка чаралар оештыру һәм үткәрү юлы белән;

9) яшьләрнең физик культура, спорт белән шөгыльләнүе өчен шартлар тудыру, сәламәт яшәү рәвешенә һәм аны яшьләр арасында популярлаштыруга булышлык күрсәтү, яшьләрнең социаль бурычларны физик культура һәм спорт аша хәл итүгә юнәлдерелгән проектларына ярдәм итү;

10) яшьләргә социаль хезмәтләр күрсәтү;

11) яшьләрнең, яшь гаиләләрнең торак проблемаларын хәл итүгә булышлык күрсәтү;

12) яшь гаиләләргә ярдәм итү, яшьләр арасында традицион гаилә кыйммәтләрен һәм гаиләле тормыш рәвешен саклау һәм ныгыту;

13) яшьләргә белем бирүгә, яшьләрнең фәнни, фәнни-техник эшчәнлегенә булышлык күрсәтү, яшь гражданнарның яңа белемнәр алуына, шул исәптән мөстәкыйль белем алу юлы белән, мотивациясен арттыру, яшь галимнәргә ярдәм итү;

14) хокукый агарту һәм яшьләргә хокукый мәгълүмат бирү;

15) яшьләр белән эшләү буенча белгечләр әзерләүне оештыру;

16) сәләтле булуын күрсәткән яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм булышу, яшь гражданнарның әдәби, сәнгати, фәнни һәм башка төр иҗат ирегенә хокукларын гамәлгә ашыруга булышу;

17) остазлык институтын үстерү;

18) яшьләргә хезмәт һәм эш белән тәэмин итү өлкәсендә гарантияләр тәэмин итү, яшь гражданнарны эшкә урнаштыруга, шул исәптән студентлар отрядлары аша, яшь белгечләрнең һәм яшь хезмәткәрләрнең һөнәри үсешенә булышлык күрсәтү;

19) яшьләрнең эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм итү һәм булышлык күрсәтү;

20) яшь гражданнарны авыл территорияләрен социаль-икътисадый үстерүгә җәлеп итү һәм авылда яшәү рәвешенең җәлеп итүчәнлеген арттыру аша аларга үз-үзләрен ачу өчен шартлар тудыру;

21) яшьләр иҗтимагый берләшмәләре, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән эшчәнлекне башкаручы коммерциягә карамаган оешмалар һәм яшьләрнең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары һәм оешмалар каршындагы үзидарә органнары эшчәнлегенә ярдәм итү;

22) яшьләрнең ихтыярый ярдәм итү (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашуына булышлык күрсәтү;

23) яшьләрдә экологик культура һәм экологик җаваплы караш булдыру;

24) яшьләр сәясәте өлкәсендә халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлеккә булышлык күрсәтү;

25) яшьләрнең хокук бозуларын һәм җәмәгатьчелеккә каршы гамәлләрен кисәтү;

26) гражданлык тәңгәллеген ныгытуга, яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүгә юнәлдерелгән фән, сәнгать, әдәбият

әсәрләрен һәм башка әсәрләрне булдыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән һәм (яисә) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, тарату эшчәнлегенә ярдәм итү;

27) яшьләр сәясәте мәсьәләләре буенча фәнни-аналитик тикшеренүләр үткәрү.»;

6) 8 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт ярдәме сорап мөрәҗәгать иткән яшьләр яисә балалар иҗтимагый берләшмәсенең әлеге Законда билгеләнгән таләпләргә туры килүе яшьләр сәясәте өлкәсендә башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.»;

7) 12 статьяда:

а) 1 өлештә «җирле үзидарә органнары» сүзләреннән соң «, яшьләр сәясәте учреждениеләре» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру турында мәгълүмат яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга кагылышлы рәсми статистик исәпкә алу белешмәләрен, Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау белешмәләрен, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү нәтиҗәлелеген мониторинглау, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, яшьләр сәясәте учреждениеләре, шулай ук яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы башка оешмалар тарафыннан үз функцияләрен башкарганда алына торган бүтән белешмәләрне үз эченә ала.»;

8) 13 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглау Татарстан Республикасында яшьләр хәле турында доклад (алга таба – доклад) әзерләү максатларында Татарстан Республикасында яшьләр, яшь гаиләләр һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең хәле, яшьләр сәясәте учреждениеләре эшчәнлеге, «Беренчеләр хәрәкәте» балалар һәм яшьләр гомумроссия иҗтимагый-дәүләт хәрәкәте турында, яшьләрнең мәгариф, агарту, фән, мәдәният, сәнгать, сәламәтлек саклау, физик культура һәм спорт өлкәсендә иҗтимагый файдалы эшчәнлектә катнашуы хакында, яшьләр арасында мәшгульлек һәм эшсезлек турында, яшьләр арасында милләтара (этносара) һәм конфессияара татулыкны тәэмин итү хакында, экстремист иҗтимагый яшьләр берләшмәләрен формалаштыруга, мондый берләшмәләрнең эшчәнлегендә экстремизм, агрессив милләтчелек идеологияләре чагылышларына юл куймау турында, яшьләрдә традицион Россия рухи-әхлакый кыйммәтләр нигезендә терроризм, экстремизм идеологияләренә, башка деструктив идеологияләргә нәфрәт тудыру хакында, шулай ук аларның пропагандасына каршы торучанлыкны формалаштыру турында мәгълүмат җыю, аны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү буенча системалы, комплекслы һәм планлы эшчәнлектән гыйбарәт.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 1[1] өлеш өстәргә:

«1[1]. Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелеген мониторинглау Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауның бер өлеше булып тора һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы гавами хакимият органнары һәм башка субъектлар эшчәнлеге турында мәгълүмат җыю, аны гомумиләштерү, анализлау һәм бәяләү, яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү эшчәнлегеннән гыйбарәт.»;

в) 4 өлештә «җирле үзидарә органнары,» сүзләреннән соң «яшьләр сәясәте учреждениеләре һәм» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» 2023 елның 9 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2023, № 92 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Закон максатларында патриотик тәрбия дигәндә гавами хакимият органнарының һәм патриотик тәрбиянең башка субъектларының гражданнарда Ватанга карата мәхәббәт һәм хөрмәт, аңа тугрылык һәм Ватан язмышы өчен бүгенге һәм киләчәк буыннар алдында шәхси җаваплылык хисе, Ватанны саклау буенча, шулай ук тарихи хакыйкатьне саклау һәм тарихи хәтерне саклау буенча граждан бурычын һәм конституциячел бурычларны үтәүгә әзер булуны формалаштыру, гражданнарда гомумроссия граждан тәңгәллеге (шул исәптән Татарстан Республикасы үзенчәлекләре һәм тиешле территориянең халык традицияләре нигезендә), Ватан тарихына хөрмәт һәм Ватан һәм аның гражданнары казанышлары өчен горурлык хисе формалаштыру һәм аны ныгыту буенча, гражданнарның иҗтимагый әһәмияткә ия иҗади активлыгын үстерү буенча системалы һәм максатчан эшчәнлеге аңлашыла.»;

2) 3 статьяның 3 өлешендәге 2 пунктында «гореф-гадәтләренә» сүзләреннән соң «, җирле гореф-гадәтләргә» сүзләрен өстәргә;

3) 5 статьяда:

а) 5 пунктта «яшьләр сәясәте, физик культура һәм спорт өлкәсендәге дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль физик культура һәм спорт оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 5[1] пункт өстәргә:

«5[1]) Яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек алып баручы субъектлар;»;

4) 6 статьяда:

а) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3[1] пункт өстәргә:

«$3^{1}$) Россия Федерациясендә территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү чаралары комплексында каралган нигезләмәләрне, яшьләрнең социаль ихтыяҗларын, милли гореф-гадәтләрне, региональ, җирле һәм Татарстан Республикасының этномәдәни үзенчәлекләрен исәпкә алып, яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү буенча региональ чаралар комплексын раслау һәм аны гамәлгә ашыруны оештыру;»;

б) 5 өлешкә:

түбәндәге эчтәлекле $4^{1}$ һәм $4^{2}$ пунктлар өстәргә:

«$4^{1}$) билгесез хәрби каберлекләрне һәм җирләнмәгән мәетләрне табу, Ватанны саклаганда һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен ачыклау һәм аларның хәтерен мәңгеләштерү максатларында гамәлгә ашырыла торган эзләү эшен үткәрүгә вәкаләтле патриотик тәрбия бирү үзәкләре, хәрби-патриотик берләшмәләр (клублар), тарихи туган як һәм эзләү оешмалары, иҗтимагый-дәүләти һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү;

$4^{2}$) яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерциягә карамаган оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә ярдәм итү;

түбәндәге эчтәлекле $5^{1}$ пункт өстәргә:

«$5^{1}$) Татарстан Республикасы территориясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирү һәм яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү нәтиҗәлелеген мониторинглау;».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында»**
**Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

2024 елның 28 декабрендә «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 550-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) кабул ителде.

Федераль закон белән яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, яшьләр сәясәте юнәлешләрен, шулай ук яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруга мониторинг ясауга кагылышлы мәсьәләләрне, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мәгълүмати тәэмин итүне регламентлаштыра торган нигезләмәләр һәм башкалар үзгәртелде.

Федераль закон дәрәҗәсендә беренче тапкыр «яшьләргә патриотик тәрбия бирү», «яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирү» төшенчәләре кертелде, яшьләргә патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү өлкәсендә гавами хакимият органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләр билгеләнде, шулай ук Россия Федерациясендә яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең нәтиҗәлелегенә мониторинг ясау каралган.

Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы законы проекты федераль законнарның югарыда күрсәтелгән нигезләмәләрен үстерүгә әзерләнде.

Закон проектында «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законы белән беркетелгән Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләре, яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре яңа редакциядә бәян ителә.

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының яшьләр сәясәте өлкәсендә җирле үзидарә органнарының вәкаләтләрен билгели торган 6 статьясына 2 өлеш өстәлә, аның нигезендә муниципаль берәмлекләр башлыкларына яшьләр сәясәте өлкәсендә координация органнары төзү хокукы бирелә.

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законының Татарстан Республикасы территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны регламентлаучы 13 статьясына нигезләмәләре яшьләргә патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирүнең нәтиҗәлелегенә мониторинг үткәрү турындагы нигезләмәләр белән өстәлә. Татарстан Республикасы территориясендә мондый мониторинг Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы тарафыннан үткәреләчәк. Бу вәкаләт шулай ук «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясында да беркетелә.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законында федераль законнар нигезендә патриотик тәрбия төшенчәсе яңа редакциядә бәян ителә, ул хәзер гавами хакимият

органнарының һәм патриотик тәрбиянең башка субъектларының гражданнарда Ватанга карата мәхәббәт һәм хөрмәт, аңа тугрылык һәм Ватан язмышы өчен бүгенге һәм киләчәк буыннар алдында шәхси җаваплылык хисе, Ватанны саклау буенча, шулай ук тарихи хакыйкатьне саклау һәм тарихи хәтерне саклау буенча граждан бурычын һәм конституциячел бурычларны үтәүгә әзер булуны формалаштыру, гражданнарда гомумроссия граждан тәңгәллеге (шул исәптән Татарстан Республикасы үзенчәлекләре һәм тиешле территориянең халык традицияләре нигезендә), Ватан тарихына хөрмәт һәм Ватан һәм аның гражданнары казанышлары белән горурлану хисе формалаштыру һәм аны ныгыту буенча, гражданнарның иҗтимагый әһәмияткә ия иҗади активлыгын үстерү буенча системалы һәм максатчан эшчәнлеген аңлата.

Патриотик тәрбия субъектлары исемлегенә яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы субъектлар өстәлә.

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә түбәндәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына үзгәрешләр кертү таләп ителә:

«Татарстан Республикасында балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирү концепциясен раслау турында» 2014 елның 16 сентябрендәге 666 номерлы;

«2030 елга кадәр Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 елның 4 февралендәге 63 номерлы;

«Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрлыгы мәсьәләләре» 2018 елның 11 июлендәге 563 номерлы;

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлекне координацияләү турында» 2022 елның 9 августындагы 778 номерлы.

**«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында»Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына һәм «Татарстан Республикасында гражданнарга патриотик тәрбия бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.